Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районының «Чабаксар авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге составына керүче Рус. Чабаксар авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
КАРАРЫ

2019 елның 15 ноябре № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 - ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы «Чабаксар авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Чабаксар авыл җирлеге Советының 2019 елның 10 октябрендәге 63-115 номерлы "Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Чабаксар авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында" карары нигезендә, 2019 елның 15 ноябрендә Яңа Чишмә муниципаль районының Чабаксар авыл җирлегендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча түбәндәге мәсьәләләр каралу турында җыенның беркетмәсе төзелде: "2020 елда Яңа Чишмә муниципаль районының Рус. Чабаксар авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән (көндезге формада укучы студентлардан кала) 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерелү белән килешәсезме:

- юлларны кардан чистарту;
- җәйге вакытта территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, эшләр һәм килешү буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру;;
- су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материал, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру, килешү буенча эш өчен түләү

«РИЗА" "КАРШЫ" "ТЫЕЛУЧЫЛАР".

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегендә барлыгы 127 граждан, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар санына 70 граждан кертелгән.

Ачык (яшерен) тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
"Риза» позициясе өчен 61 граждан тавыш бирде;
"Каршы" позициясе өчен 9 граждан тавыш бирде.
"Тыелучылар» позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде.

Югарыда бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Чабаксар авыл җирлеге Рус. Чабаксар авылында халык җыены узган, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә, дип танырга.
2. Түбәндәге мәсьлә буенча кабул ителгән карарны танырга: «2020 елда Яңа Чишмә муниципаль районының Чабаксар авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны

буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән (көндезге формада укучы студентлардан кала) 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерелү белән килешәсезме:

- юлларны кардан чистарту;
- җәйге вакытта территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, эшләр һәм килешү буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру;;
- су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материал, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру, килешү буенча эш өчен түләү

3. Әлеге карарны Чабаксар авыл җирлегенең мәгълүмати стендлары аша халыкка җиткерергә, Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

ТР Яңа Чишмә муниципаль районы
Чабаксар авыл җирлеге Башлыгы С.В.Моляков